## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАРЫ

**2018 елның 20 марты 112N**

### Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының "Әлки муниципаль районы территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру турында" 515 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 29 декабрендәге "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законга үзгәрешләр кертү турында" 480-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Әлки муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә үзгәрешләр кертергә (2 нче кушымта):

- 3 пунктның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 1.3.1 пунктчасы өстәргә:

"1.3.1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын яки даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутын билгеләү яисә үзгәртү әлеге Федераль закон нигезендә компетенцияләренә әлеге маршрутларны билгеләү кертелгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы һәм җирле үзидарәнең вәкаләтле органы арасында килештерү буенча гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән килештерү тәртибе закон яисә Россия Федерациясе субъектының башка норматив хокукый акты белән билгеләнә."

- 3 пунктның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 2.3.1 пунктчасы өстәргә:

"2.3.1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсе буенча аның вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы инициативасы буенча тиешле маршрутны үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турындагы карарны әлеге таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланган көнгә кадәр йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча кабул итә һәм мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән үз көченә керә.”

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары С.Н. Балакиревка йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И. В. И.В. Юсупов

"Әлки муниципаль районы территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру турында" 515 нче номерлы (Чыганак: "КОДЕКС" ИСС).